БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 октябрь 2022 ел № 147

**Балтач муниципаль районында Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен бушлай алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен әзерләү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32.1 статьяларына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә һәм Балтач районы прокуратурасының 2022 елның 16 сентябрендәге 02-08-01/Прдп168-22-20920011 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. 2012 елның 21 гыйнварындагы 82 номерлы (2019 елның 15 мартындагы 174 номерлы үзгәрешләр белән) карары белән расланган Балтач муниципаль районында Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә җир кишәрлекләрен бушлай алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен әзерләү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәптә торучы.

Әгәр дә атасы яисә анасы яки бердәнбер ата-ана җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәсә, өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү турындагы таләп каралган пунктка туры килә дип санала.

Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар дигәндә составында өйләнешкән яисә өйләнешмәгән, әмма бергә торучы ата-ана (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр) яисә атасы яки анасы (уллыкка алучы, опекун, попечитель) (алга таба - ата-ана, атасы яисә анасы), шулай ук җир кишәрлеген милеккә бирү (тапшыру) турында гариза тапшыру датасына кадәр унсигез яше тулмаган өч һәм аннан да күбрәк бала, шул исәптән үги уллар, үги кызлар, уллыкка (кызлыкка) алынган һәм опека алынган бала

(аларга карата опека һәм попечительлек чикләнмәгән вакытта башкарыла яки алар балигъ булу яшенә житкәнче) булган күпбалалы гаилә аңлашыла.

14 пунктка

- түбәндәге эчтәлекле 7, 8 һәм 9 пунктчалар өстәргә:

«7) язылышу турында таныклык (ата-ана язылышкан булган очракта);

8) мөрәжәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак бинада мохтаж буларак исәптә торуын раслый торган документ;

9) жир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында мөрәжәгать итүченең Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турында суд карары (мөрәжәгать итүче паспортында жир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга булмаган очракта).».

- түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр мөрәжәгать итүче әлеге пунктның 8 пунктчасында күрсәтелгән документны үз инициативасы белән тапшырмаган булса, ул жирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә соратып алына.».

18 пунктта:

- «мөрәжәгать итүче тарафыннан тапшырылган» сүзләреннән соң «яисә жирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан алынган» сүзләрен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Гражданнарны исемлеккә кертүдән баш тарту турында аларга хәбәр итү жирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көннән алып жиде көннән дә соңга калмыйча тапшыру турында хәбәрнамәле заказлы хат белән яисә хәбәр кәгазен имза куйдырып бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.";

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстемә алам.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р. Нотфуллин